УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ
ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ
СОСТОЯНИЕМ
САМОХОДНЫХ МАШИН И
ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ
БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ
ТЕХНИК ТОРЫШЫНА
КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** | Казан шәһәре | **БОЕРЫК**

01.03.2022 | № 01-05/69 - пр

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары турында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясындагы 4 өлеше һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1064 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе турындагы нигезләмә нигезендә,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген (кушымтада бирелә) расларга.
2. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең «Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары турында» 2020 елның 20 августындагы 01-05/105-пр санлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче Р.Р. Зыятдинов

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең 2022 елның 1 мартындагы 01-05/69-пр санлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге

Идарә җитәкчесе – Татарстан Республикасының үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә күзәтчелек буенча баш дәүләт инженер-инспекторы;

Идарә җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасының үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә күзәтчелек итү буенча баш дәүләт инженер-инспекторы урынбасары;

территориаль бүлекләр җитәкчеләре – үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торышы һәм алардан файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Татарстан Республикасы шәһәрләрендә (районнарында) баш дәүләт инженер-инспекторлары;

территориаль бүлекләрнең консультантлары – үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә күзәтчелек буенча Татарстан Республикасы шәһәрләре (районнары) дәүләт инженер-инспекторлары;

тиешле рәвештә баш дәүләт инженер-инспекторы һәм үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә күзәтчелек буенча дәүләт инженер-инспекторлары булып торган күзәтчелек һәм автоматлаштырылган нигездә исәпкә алу бүлеге җитәкчесе һәм вазыйфаи затлары;

тиешле рәвештә баш дәүләт инженер-инспекторы һәм үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың, аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә күзәтчелек буенча дәүләт инженер-инспекторлары булып торган аттракционнарга күзәтчелек һәм махсус юл транспортына карата дәүләт контроле бүлеге җитәкчесе һәм вазыйфаи затлары.